Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

17 ноябрь, 2021 ел № 4

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында» 2021 елның 19 октябрендәге 1 номерлы район башлыгы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авылы җирлеге уставы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә (2017 елның 21 августындагы 30 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 12 номерлы, 2019 елның 07 октябрендәге 52 номерлы карарлар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе хакындагы нигезләмә нигезендә, җирлектә яшәүчеләрнең Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының тормыш эшчәнлеге, хокук ияләренең һәм законлы мәнфәгатьләренең уңай шартларына хокукларын үтәү максатларында **карар бирәм**:

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында» 2021 елның 19 октябрендәге 1 номерлы Шәле авыл җирлеге башлыгы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1.1.пунктын **түбәндәге редакциядә бәян итәргә**:

«3.1.1. Генераль план проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру датасын, вакытын һәм урынын билгеләргә:

- Шәле авылында яшәүчеләр өчен: 2021 елның 6 декабрендә 10.00 сәгатьтә Шәле мәдәният йортының тамашачылар залы (422796, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Шәле ав., Хәйруллин ур., 35);

- Люткино авылында яшәүчеләр өчен: 2021 елның 6 декабрендә 12.00 сәгатьтә торак йорт янында (422796, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Люткино авылы, Спас урамы, 10 йорт);

- ТатЦИК ис. авыл кешеләре өчен: 2021 елның 6 декабрендә 14.00 сәгатьтә кибет янында (422796, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, ТатЦИК ис. авыл, Совет ур., 12а йорт) була.»

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») район газетасында Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге башлыгы И.Р. Әхмәтҗанов